# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
# **КАРАРЫ**

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру кирәклеге турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

1. Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә матди һәм социаль гарантияләрне арттыру кирәклеге турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга җибәрергә.

3. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 марты
№ 1365-VI ДС

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә
матди һәм социаль гарантияләрне арттыру кирәклеге турында
Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Татарстан Республикасында узган елда хезмәттән киткән полиция хезмәткәрләренең саны шактый артты.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматы буенча, 2021 елда республиканың эчке эшләр органнарыннан 1 659 хезмәткәр эштән киткән. (Чагыштыру өчен: 2020 елда бу күрсәткеч – 966).

Шуларның 56,1% үз теләге белән, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукы бирә торган тиешле яшькә җиткәнче, киткән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эчке эшләр органнарының кадрлар белән тәэмин ителешенә бәйле вәзгыятькә борчылуын белдерә. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр органнарында шәхси составның тиешле санда булмавы 12% тәшкил итә. Хезмәттән тикшерү, сорау алу, җинаятьчеләрне эзләү, патруль-пост хезмәте кебек төп бүлекләр хезмәткәрләре, шулай ук участок полициясе хезмәткәрләре китә.

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең агымдагы елның февраль аенда үткән киңәйтелгән утырышында әлеге проблеманың Россия Федерациясе масштабында актуаль булуы расланды. Аерым алганда, Россия Федерациясе Эчке эшләр министры В.А. Колокольцев чыгышында эчке эшләр органнарыннан эштән киткән хезмәткәрләр санының даими арта баруы билгеләп үтелде. Мәсәлән, 2021 елда эчке эшләр органнарыннан эштән киткән тикшерүчеләр саны, 2020 ел белән чагыштырганда, 34% арткан. Мондый тискәре тенденция, үз чиратында, кадрларның тагын да китүенә китерә, чөнки хезмәткәрләрнең тиешле санда булмавы шартларында калган хезмәткәрләр өстәмә йөкләмә алып эшләргә мәҗбүр була.

Полиция хезмәткәрләренең хезмәттән китүенең төп сәбәбе – акчалата түләүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы. Полиция хезмәткәрләренең еш кына тормыш һәм сәламәтлек өчен куркыныч булган һөнәри эшчәнлегенең җәмгыять өчен мөһим булуына карамастан, аларның матди тәэмин ителеше ярамаслык дәрәҗәдә түбән булып кала.

2011 елда «Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында хезмәт итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 342-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителгәндә, шәхси составка акчалата түләүне ел саен индексацияләү каралган иде. Әмма 2012 елдан алып 2018 елга кадәр мондый индексация ясалмады.

Моннан тыш, полиция хезмәткәрләре өчен билгеләнгән ташламаларны гамәлгә ашыру дәрәҗәсенең җитәрлек булмавы җитди проблема булып тора.

Хәзерге көндә Татарстан Республикасында торак сатып алуга яисә төзүгә бер мәртәбә бирелә торган социаль түләүне алу чиратында 2 574 хезмәткәр тора. Ел саен мондый түләү уртача 70 чираттагы кешегә бирелә. Шул рәвешле, түләүгә чиратта торуның уртача вакыты 36 ел тәшкил итә.

Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең торак проблемасын хәл итүдә торак урыннарны наемга (өстәмә рәвештә наемга) алу өчен гамәлдәге компенсацияләү механизмы да ярдәм итми. 2021 елның декабренә Казан шәһәрендә бер бүлмәле фатирны арендалауның уртача бәясе 18 мең сум тәшкил итте. Әмма Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 30 декабрендәге 1228 номерлы карарының 2.1 пункты нигезендә хезмәт урыны буенча торак урыны булмаган хезмәткәрләргә акчалата компенсация 3 600 сумнан да артмаган күләмдә (бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә) түләнә.

Законнарда пенсияне хезмәттән азат ителгәннән соң гына алу мөмкинлеге каралганга күрә, аны алу хокукына ия хезмәткәрләрнең эчке эшләр органнарында алга таба да хезмәт итү мотивациясенең булмавы кадрлар нигезен саклап калуга тискәре йогынты ясый.

Законнарда эчке эшләр органнары хезмәткәрләрен хәрби хезмәткә чакыруны кичектереп тору да каралмаган, бу исә шулай ук күп кенә гражданнар өчен эчке эшләр органнарына эшкә урнашу турындагы карардан тыелып тору факторы булып тора.

Барлыкка килгән вәзгыятькә борчылуны белдереп, Татарстан Республикасы парламенты әйтелгән проблемаларны хәл итү максатларында Сездән федераль законнарга түбәндәге өлештә үзгәрешләр кертү мөмкинлеген карауны сорый:

– эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә акчалата түләүне арттыру;

– эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә Россия Федерациясе хәрби хезмәткәрләрен торак белән тәэмин итүнең тупланма-ипотека системасы кебек үк система нигезендә фатир сатып алу мөмкинлеген бирү;

– эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен торакны арендалауга түләүләр күләмен яшәү регионындагы аренда бәясенең уртача базар дәрәҗәсенә кадәр арттыру;

– эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә ял итү урынына баруга түләү өчен ташламалар билгеләү;

– эчке эшләр органнары хезмәткәрләре өчен барлык төр шәһәр җәмәгать транспортында йөрүгә ташламалы билет сатып алу мөмкинлеге;

– эш вакытының билгеләнгән дәвамлылыгыннан 240 сәгатькә яисә 30 көнгә кадәр арттырып эшләгән өчен акчалата компенсацияне арттыру;

– пенсиягә чыгу хокукы булган эчке эшләр органнарының эшләүче хезмәткәрләренә аларга хезмәттән азат ителгән очракта билгеләнергә мөмкин булган пенсия күләменнән процент нисбәтендә өстәмә билгеләү;

– эчке эшләр органнарында хезмәт үтүче гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны кичектереп тору.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр эчке эшләр органнары шәхси составының кадрлар нигезен саклап калу һәм гражданнар өчен полиция органнарында хезмәт итүнең җәлеп итүчәнлеген арттыру мөмкинлеген бирәчәк.